ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСАНДРО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛЕКСАНДР БИСТӘСЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22.05.2026** Александр Бистәсе ав. **№ 8**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2012 елның 14 мартындагы 8 номерлы карарының "Александр Бистәсе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында " үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 14 мартындагы 8 номерлы «Муниципаль берәмлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **А.С. Кузнецов**